КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 март г.Казань № 239

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 февраль, 103 нче; 2015 ел, 11 март, 144 нче; 2016 ел, 24 март, 164 нче; 2016 ел, 15 август, 563 нче; 2017 ел, 21 февраль, 111 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 951 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 858 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацында «ТР Законы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Законы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасындагы 1 пунктында:

«л» пунктчасының икенче абзацында татар текстында «никахны теркәү» сүзләрен «никахлашу» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле ««н» – «п» пунктчаларын өстәргә:

«н) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар – Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт узган чорда – гражданның Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу фактын раслый торган документ;

о) Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрендә катнашу шарты белән ирекле формированиедә булу турында (Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында) контракт (алга таба – контракт) төзегән гражданнар – ирекле формированиедә булу турында (Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында) контракт гамәлдә булу чорында – контракт төзү (гамәлдә булу) фактын раслый торган документ;

п) «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 өлешенең $8^3$ һәм $8^4$ пунктларында күрсәтелгән гражданнарның гаилә әгъзалары – гражданның Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу фактын раслый торган документ йә контракт төзү (гамәлдә булу) фактын раслый торган документ, шулай ук:

1) ата-аналар (уллыкка алучылар) – Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданның йә контракт төзегән гражданның туу турында таныклык күчермәсен яисә әлеге граждан белән туганлыкны раслый торган суд карары күчермәсен;

2) ире (хатыны) – никахлашу турында таныклык күчермәсен;

3) балигъ булмаган, шул исәптән уллыкка алынган, тәрбиягә алынган һәм опекада (попечительлектә) булган балалар – Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданның йә контракт төзегән гражданның баласы туу турында таныклык күчермәсен, яисә әлеге граждан белән баланың туганлыгын раслый торган суд карары күчермәсен, яисә баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тәрбияләүгә бирү турында документ күчермәсе, яисә балага опека (попечительлек) билгеләү турында документ күчермәсен;

4) 18 яше тулганга кадәр инвалид булган 18 яшьтән өлкәнрәк балалар:

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданның йә контракт төзегән гражданның туу турында таныклык күчермәсе яисә әлеге граждан белән туганлыкны раслый торган суд карары күчермәсен;

федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениесе тарафыннан бирелгән инвалидлыкны билгеләү фактын раслый торган белешмә кәгазе күчермәсен;

5) мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар:

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданның йә контракт төзегән гражданның туу турында таныклык күчермәсе яисә әлеге граждан белән туганлыкны раслый торган суд карары күчермәсен;

мәгариф оешмасында көндезге бүлектә белем алу фактын раслый торган белем бирү оешмасының белешмә кәгазен;

6) иждивениедәге затлар – затның Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган граждан йә контракт төзегән граждан карамагында тулысынча булуын яки аның өчен даими һәм төп яшәү чыганагы булган ярдәм алуны раслый торган документ яисә затның әлеге граждан карамагында тулысынча булуын яки аның өчен даими һәм төп яшәү чыганагы булган ярдәм алуны раслый торган суд карары күчермәсен.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин